ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.16, с. Кильдеево, 422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 16 нче йорт, Килди авылы, 422586

Тел.: (84379) 34-7-41, факс: (84379) 34-7-41.

20.11.2025 № 1

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Килди авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Килди авылы җирлегенең Килди авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү - янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү белән килешәсезме? дигән сорау буенча 2025 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 166 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 87 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 87 катнашучы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авылы җирлегенең Килди авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип таныргa.

«Югары Ослан муниципаль районының Килди авылы җирлегенең Килди авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категориядәге гражданнардан тыш, Югары Ослан муниципаль районының Килди авылы җирлегенең Килди авылында 2026 елда 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү - янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү белән килешәсезме? дигән сорау буенча карар кабул итәргә.

2. Югары Ослан муниципаль районы Килди авылы җирлегенең Килди авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Килди авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче В. М. Бурдин